| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.05.2019 с. Большие Кайбицы № 261

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2019елның 29мартындагы 151 номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда тикшерүнең Административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

2008нче елның 26нчы декабрендә чыккан 294-ФЗ номерлы «Юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең дәүләт контроле (күзәтүе) һәм муниципаль контроль башкарганда хокукларын саклау турында» Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР КЫЛА:

1.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2019елның 29мартындагы 151 номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда тикшерүнең Административ регламентын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1нче Кушымтаның 2.1.2. пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.1.2. Планнан тыш күчмә тикшерүне, үткәрү нигезе «Юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең дәүләт контроле (күзәтүе) һәм муниципаль контроль башкарганда хокукларын саклау турында" Федераль законның 10 статьясы 2өлеше 2 пунктында күрсәтелгәннән тыш, юридик затка, шәхси эшмәкәргә дәүләт контроле (күзәтүе) органы тарафыннан аны башлаганчы кимендә 24 сәг алдан теләсә нини уңайлы ысул белән хәбәр ителә, шул исәптән электрон почтасы юридик затларның дәүләт реестрында булса, шәхси эшмәкәрләрнең дәүләт реестрында булса, яисә дәүләт контроле (тикшерүе) органына юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан җиткерелгән булса, квалификацияле көчәйтелгән электрон имзалы документ белән электрон адреска җибәрелә.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнашкан “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче

А.Н.Макаров